**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы № 121 28 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдулловский сельское поселение» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы 2013 елның 07 октябрендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын хупларга.(18.03.2014 №98, 16.08.2014 №116, 25.08.2017 №65 карарлар редакциясендә)» (Кушымта №1).

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы 2013 елның 07 октябрендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты - 2018 елның 9 декабреннән 2018 елның 11 гыйнварына кадәр;

- үткәрелү урыны - Чубар Абдул авылы, Совет урамы, 85 йорт;

- 2018 елның 11 гыйнварына кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелергә мөмкин булган адрес – Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 81 нче йорт, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Гавами тыңлауларны үткәрү буенча эшче төркем төзергә:

- Фәтхетдинов Нияз Әдхәт улы – Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы;

- Рәфыйков Гаптеләхәт Гатуф улы . - Чубар-Абдул авыл җирлеге 1 нче округ

депутаты

-Шәфигуллин Рафаэль Гамбәр улы - Чубар-Абдул авыл җирлеге  7 нче округ депутаты

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы 2013 елның 07 октябрендәге  карары белән расланган  Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча (18.03.2014 №98,  16.08.2014 №116,  25.08.2017 №65 карарлар редакциясендә) гавами тыңлаулар уздыру буенча эшче төркемгә гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итү, кабул итү һәм гражданнарның проект буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, чираттагы утырышны карауга кертергә тиеш.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

8.  Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис　　　　　　　　　　　Н.А. Фәтхетдинов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул

авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 28 ноябрендәге 121 номерлы карарына кушымта

**ПРОЕКТ**

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы №___ __ _________ 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы 2013 елның 07 октябрендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (18.03.2014 №98, 16.08.2014 №116, 25.08.2017 №65 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы 2013 елның 07 октябрендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (18.03.2014 №98, 16.08.2014 №116, 25.08.2017 №65 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3 пунктта:

3.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«территорияне төзекләндерү – әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән, гражданнарның яшәү шартларының уңайлылыгын тәэмин итүгә һәм арттыруга, шәһәр территориясенең санитар һәм эстетик торышын карап тотуга һәм яхшыртуга, шәһәр территориясен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, янәшә территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге»;

б) түбәндәге эчтәлекле унҗиде абзац өстәргә:

«төзекләндерү элементлары – шул исәптән биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның фасадларының декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалары, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, кече архитектура формалары, капиталь булмаган, стационар булмаган төзелмәләр һәм корылмалар, территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләр»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 4.6 пунктны өстәргә:

«7.17. Йорт билгеләрендәге, тышкы мәгълүмат чараларындагы мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәгән килеш урнаштырылырга тиеш. Ике яки аннан да күбрәк тел кулланган очракта, текстлар эчтәлек һәм техник бизәлеш буенча тиңдәш булырга, грамоталы һәм аңлаешлы итеп башкарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.